**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**27.02.2018** **№ 520**

**Биектау муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларына беренче сыйныфка алты яшь тә алты айдан кечерәк һәм сигез яшьтән өлкәнрәк балаларны кабул итү тәртибен раслау турында**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законның 67 ст. 1 пункты, Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алуга гражданнарны кабул итү тәртибен раслау турында» 2014 елның 22 гыйнварындагы 32 номерлы боерыгы, Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Төп гомуми белем бирү программалары - башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру тәртибен раслау турында» 2013 елның 30 августындагы 1015 номерлы боерыгы, гомуми белем бирү учреждениеләрендә белем бирү шартларына һәм оешмаларына Санитар-эпидемиологик таләпләр нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Агымдагы елның 1 сентябренә 6 яшь тә 6 айга җитмәгән һәм 8 яшьтән өлкәнрәк балаларны гомуми белем бирү оешмаларының 1 сыйныфына кабул итү тәртибен (1 нче кушымта) расларга.
2. Балаларны белем бирү оешмаларына башлангыч гомуми белемнең белем бирү программалары буенча кечерәк яисә олырак яшьтә укырга алу турында ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) гаризаларны карау өчен комиссияне (2 нче кушымта) нигезендә расларга.
3. Балаларны башлангыч гомуми белемнең белем бирү программалары буенча кечерәк яисә олырак яшьтә укырга кабул итү турында ата-аналарның (законлы вәкилләренең) гаризаларын карау буенча комиссия эше турындагы нигезләмәне расларга (3 нче кушымта).
4. Әлеге карарны интернет челтәрендә «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адресы буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация

челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитет җитәкчесе урынбасары - Биектау муниципаль районы мәгариф бүлеге башлыгы Н.К. Әхмәтҗановка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Д.Ф. Шәйдуллин

1 нче кушымта
«Расланды»
ТР Биектау муниципаль
районы башкарма
комитетының 2018 елның
27 февралендәге 520 номерлы
карары белән

**Агымдагы елның 1 сентябренә 6 яшь тә 6 айга җитмәгән һәм 8 яшьтән өлкәнрәк балаларны гомуми белем бирү оешмаларының 1 сыйныфына кабул итү тәртибе**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының белем бирү оешмаларына башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укуга кечерәк яисә олырак яшьтәге балаларны кабул итүне регламентлаштыра.

1.2. Әлеге Тәртип түбәндәге норматив документлар нигезендә эшләнгән:

- «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль закон;
- Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алуга гражданнарны кабул итү тәртибен раслау турында» 2014 елның 22 гыйнварындагы 32 номерлы боерыгы;
- Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Төп гомуми белем бирү программалары - башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру тәртибен раслау турында» 2013 елның 30 августындагы 1015 номерлы боерыгы;
- гомуми белем бирү учреждениеләрендә белем бирү шартларына һәм оешмаларына Санитар-эпидемиологик таләпләр. СанПиН 2.4.2.2821-10.

1.3. Мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем алу сәламәтлеге торышы буенча каршылыклар булмаганда, балаларга алты яшь тә алты ай тулгач башлана, ләкин алар сигез яшькә җиткәннән дә соңга калмыйча. Балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) гаризасы буенча белем бирү оешмасын гамәлгә куючы балаларны башлангыч гомуми белем бирүнең уку-укыту программалары буенча укырга кечерәк яисә олырак яшьтәге алуны рөхсәт итәргә хокуклы.

1.4. Уку елы башлануга алты яшь тә алты айга җитмәгән балаларны укытуны, мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен белем бирү процессы шартларына һәм оештыруга карата барлык гигиена таләпләрен үтәп, мәгариф оешмасында үткәрергә кирәк.

## 2. Эшне оештыру

2.1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының белем бирү оешмаларына балаларны башлангыч гомуми белем бирүнең уку-укыту программалары буенча укырга рөхсәт бирү балаларның ата-аналарыннан (законлы вәкилләреннән) гомуми белем бирү оешмаларының 1 сыйныфына 6 яшь тә 6 айга

җитмәгән балаларны һәм 8 яшьтән өлкәнрәк балаларны кабул итү турындагы гаризаларын карау буенча комиссия тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2.2. Балаларны башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем алуга кабул итүгә рөхсәт алу өчен, белем бирү оешмасының кечерәк яисә олырак яшьтә белем бирү оешмаларында түбәндәге документлар белән гариза тапшырырга кирәк:

- ата-ананың (законлы вәкилләрнең) билгеләнгән тәртиптә таныкланган гаризасы күчермәсе;

- баланың туу турында таныклыгының билгеләнгән тәртиптә таныкланган күчермәсе;

- сәламәтлеге торышы буенча каршылыклар булмауны раслый торган документның күчермәсе (бала алты яшь тә алты айга җитмәгән очракта: психологик-медик-педагогик комиссия бәяләмәсе; «Биектау район үзәк хастаханәсе» ДАССУ бәяләмәсе белән медицина картасы «Укырга рөхсәт ителгән ______яшьтән»).

2.3. Ата-ана (законлы вәкилләр) тарафыннан язылган гариза учреждение җитәкчесе тарафыннан учреждениене гамәлгә куючыга баланы кабул итү турында карар кабул итү һәм килештерү өчен җибәрелә.

2.4. Гаризаларны карау срогы - гамәлгә куючыга кергән саен.

2.5. 6 яшь тә 6 айдан кечерәк һәм 8 яшьтән өлкәнрәк балаларны учреждениегә кабул итү мәсьәләләрен карау комиссиясе материалларны, бирелгән документларны өйрәнеп, 6 яшь тә 6 айдан кечерәк баланы укыту өчен рөхсәт бирү яисә кабул итүдән баш тарту турында карар кабул итә, 8 яшьтән өлкәнрәк баланы белем алу формасын һәм укыту рәвешен билгели. Тәкъдим ителгән документлар ата-аналар, законлы вәкилләр, мәгариф оешмасы вәкилләре катнашында комиссия утырышында карала. Кабул ителгән карар комиссия утырышы беркетмәсендә теркәлә.

2.6. Баланы 1 нче сыйныфка алу турында рөхсәт алганнан соң, ата-аналар (законлы вәкилләр) учреждениегә тиешле гариза бирәләр.

2.7. Учреждение җитәкчесе гомуми белем бирү учреждениеләрендә белем бирүне оештыру шартларына карата санитар-эпидемиологик таләпләр (СанПиН 2.4.2.2821-10) нигезендә укучыларның әлеге категориясен укыту өчен шартлар тәэмин итәргә тиеш.

## 3. 8 яшьтән өлкәнрәк балаларны беренче сыйныфка алу тәртибе

3.1. 8 яшькә җиткән баланы беренче сыйныфка кабул иткәндә, ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) гаризасында баланы мәктәпкә вакытында билгеләмәү сәбәпләрен аңлату булырга тиеш.

3.2. Учреждение өч көн эчендә балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенә (алга таба ─ КДН һәм ЗП) һәм Мәгариф бүлегенә ата-аналар (законлы вәкилләр) тарафыннан "Россия Федерациясендә мәгариф турында" 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ РФ номерлы Федераль законының 67 ст. 1 пункты бозылу турында хәбәр итә.

3.3. 8 яшьтән өлкәнрәк балаларны мәктәпкә алу турында гариза бирү срокларын бозу ата-аналарга (законлы вәкилләренә) баланы учреждениедә укытудан баш тарту өчен нигез була алмый.

3.4. 8 яшьтән өлкәнрәк баланы беренче сыйныфка кабул иткәндә, учреждение аны озата баруны тәэмин итә, мондый баланың белем алуга әзерлеге турында бәяләмә рәсмиләштерү һәм белем бирү маршрутын билгеләү өчен психологик-медик-педагогик комиссиягә җибәрә.

2 нче кушымта
«Расланды»
ТР Биектау муниципаль
районы башкарма
комитетының 2018 елның
27 февралендәге 520 номерлы
карары белән

Ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) Биектау муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләренең 1 сыйныфына агымдагы елның 1 сентябренә 6 яшь тә 6 айга җитмәгән балаларны һәм 8 яшьтән өлкәнрәк балаларны кабул итү турындагы гаризаларын карау комиссиясе составы

| | | |
|---|---|---|
| Хөснетдинов Илшат Фәнүс улы | – | «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» МКУ җитәкчесе, комиссия рәисе; |
| Әхмәтҗанов Нияз Камил улы | – | Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары - «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы, комиссия рәисе урынбасары; |
| Хәйруллина Рузилә Хәлил кызы | – | «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУнең башлангыч белем бирү методисты, комиссия секретаре; |
| Зәйнетдинова Алия Фиркать кызы | – | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге баш белгече; |
| Кәримова Римма Камил кызы | – | Муниципаль психологик-педагогик хезмәт җитәкчесе; |
| Яриәхмәтова Альбина Наил кызы | - | Муниципаль психологик-педагогик хезмәтнең педагог-психологы; |
| Ганиева Гөлназ Илгиз кызы | - | «Биектау үзәк район хастаханәсе» ДАССУ район педиатры |

2 нче кушымта
«Расланды»
ТР Биектау муниципаль
районы башкарма
комитетының 2018 елның
27 февралендәге 520 номерлы
карары белән

**Балаларны башлангыч гомуми белемнең белем бирү программалары буенча кечерәк яисә олырак яшьтә укырга кабул итү турында ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) гаризаларын карау буенча комиссия эше турында нигезләмә**

## 1. Общие положения

1.1. Комиссия эшчәнлегенең нигезен «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль закон, Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алуга гражданнарны кабул итү тәртибен раслау турында» 2014 елның 22 гыйнварындагы 32 номерлы боерыгы, Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Төп гомуми белем бирү программалары - башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру тәртибен раслау турында» 2013 елның 30 августындагы 1015 номерлы боерыгы, Гомуми белем бирү учреждениеләрендә белем бирү шартларына һәм оешмаларына Санитар-эпидемиологик таләпләр. Санитар-эпидемиологик кагыйдәләр һәм нормативлар СанПиН 2.4.2.2821-10 билгели.

1.2. Комиссия составы Биектау район башкарма комитеты җитәкчесе карары белән билгеләнә.

## 2. Комиссиянең бурычлары

2.1. 1 сентябрьгә 6 яшь тә 6 айга җитмәгән һәм 8 яшьтән өлкәнрәк балаларны 1 нче сыйныфка кабул итүгә рөхсәт бирү турында ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) гаризаларын карау.

2.2. Бала мәнфәгатьләрен яклауга юнәлдерелгән карар кабул итү.

## 3. Комиссиянең составы

3.1. Комиссия эшчәнлегенә турыдан-туры җитәкчелекне комиссия рәисе булып торучы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе башкара; комиссия утырышлары беркетмәләрен алып бару өчен «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ методистлары арасыннан секретарь билгеләнә.

3.2. Комиссия составына Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе, башкарма комитет җитәкчесе урынбасары -“ТР Биектау муниципаль

районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге” җитәкчесе, мәгариф бүлеге методисты, муниципаль психологик-педагогик хезмәт белгечләре, опека һәм попечительлек бүлегенең баш белгече, медицина хезмәткәре (“Биектау Үзәк район хастаханәсе” ДАССУ белән килештереп) керә.

3.3. Комиссия әгъзалары үз вазыйфаларын җәмәгать башлангычларында башкаралар.

## 4. Комиссия эшен оештыру

4.1. Комиссия үз эшчәнлеген әлеге Нигезләмәнең 2 бүлегендә беркетелгән бурычлардан чыгып төзи.

4.2. 1 нче сыйныфка 6 яшь тә 6 айга җитмәгән балаларны кабул итүне рөхсәт итү турындагы гаризалар агымдагы елның 1 февраленнән 20 августына кадәр кабул ителә.

4.3. Комиссия эше сроклары ата-аналарга, гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә комиссия эшли башлаганчы бер атнадан да соңга калмыйча җиткерелә.

4.4. Чираттан тыш утырышлар ата-аналар (законлы вәкилләр) яисә гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесе үтенече буенча узарга мөмкин.

4.5. Мәсьәләне өйрәнү өчен комиссия балаларны 1 нче сыйныфка кабул итүгә кагылышлы башка документларны соратырга мөмкин.

4.6. Комиссия секретаре:

- комиссияне карау өчен материаллар әзерли;
- беркетмәләр рәсмиләштерә;
- Комиссия карарын ата-аналарга (законлы вәкилләргә), гомуми белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренә җиткерә.

4.7. Комиссия вәкаләтләре чоры 5 ел тәшкил итә.

4.8. Комиссия әгъзаларын билгеләп кую яисә аларның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турындагы карар комиссия рәисе тарафыннан кабул ителә.

4.9. Комиссия утырышы кирәк булган саен елына бер тапкырдан да ким булмаган күләмдә уздырыла.

4.10. Комиссия барлык утырышларга кызыксынучы якларны (ата-аналарны, законлы вәкилләрне, мәгариф оешмасы вәкилләрен һ.б.) чакыра, комиссия утырышы беркетмәсен рәсмиләштерә.